ТР Балтач районы Пыжмара урта мәктәбе

# Әдәби- музыкаль кичә

# Шагыйрә Резеда Вәлиева белән очрашу кичәсе

**Төзеде: 1 категорияле татар теле**
**һәм әдәбият укытучысы**
**Латипова Р.Г.**

# *Шагыйрә Резеда Вәлиева белән очрашу кичәсе*

**(Җыр "Безнең туган як". Башлангычлар башкара.)**

**1 А.б.** *Балалар әдибе! Балалар шагыйре! Балалар язучысы! Бу исемгә лаек булу өчен иҗатчыга тумыштан килгән табигый талантлан тыш күңел сафлыгын, риясыз сабый омтылышларын, балачакның ихлас хыялларын, балалар зиһене генә ирешә ала торган үткенлекне, зирәклекне һәм тагын башка бик күп сыйфатларны гомер буена саклый белергә кирәк. Менә шундый бик күп уңай сыйфатларга ия булган, балалар күңелен яулап алган шагыйрә бүген безнең арада. Рәхим итеп түргә узыгыз Резеда апа!*

**2 А.б.** Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе шагыйрә Резеда Тәфкалүн кызы Вәлиева 1930 елның 1 маенда Башкортстан Республикасы Кыйӱчы районы Дүшәмбикә авылында укытучы гаиләсендә туган. Әтисе Тәфкалүн Хәммәт улы Россиянең атказанган укытучысы, 2 Ленин ордены иясе, 40 ел укытучы һәм мәктәп директоры булып эшләгән. Ә әнисе Марзия ханым башлангыч сыйныфларны укыткан. Әтиләре кечкенәдән рус әдәбияты белән мавыктырса, әниләре татар халык әкиятләрен, мәкальләрен, әйтемнәрен телдән төшерми, җырларын ярата, күп бәетләр белә һәм үзе дә бәетләр чыгарырга оста булган. Бу турыда шагыйрә үзе болай искә ала: "безнең өйдә һәрвакыт шигырьләр һәм җырлар яңгырап торды, өстәвенә миннән кала өебездә бөтен кеше әткәм белән әнкәм генә түгел, абыем белән апам да мандолинада уйный иде.

**Сорау. Резеда апа үзегезнең гаиләгез белән кыска гына таныштырып китсәгез иде?**

***Җыр. "Уята" Аскаров Рәмзис***

**1 А.б.** *Бала-чагы серле танышуларга, сихри кичәләргә бай булган шагыйрәнең күңелен Бөек Ватан сугышы тетрәндереп җибәрә. Язучының сугыш чоры темасына караган әсәрләре тетрәндергеч һәм уйландыра торган. Сугыш башланганда 11 яшьтә генә булган автор сугыш афәтенең үз күңеленә ни рәвешле тәэсир итүен, үзе теләп фронтка киткән апасы Рәүзиягә багышланган "Толымнарың синең" шигырендә менә ничек тасвирлый.*

***Шигырь "Толымнарың синең". Нуриева Раилә.***

**2 А.б.** *Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң булачак шагыйрәне Казан көтә. Тукай һәм Такташ Казаны!*

Аның Казанга мәхәббәте чиксез. Ул Казан каласын бик горурланып [illegible]

***Җыр. "Казаным туган калам". Кызлар.***

*Резеда апа Казан Дәүләт университетына укырга керә, туган тел һәм әдәбият белгече булырга әзерләнә.1952 елда университетны тәмамлагач Татарстан китап нәшриятендә редактор булып эшли башлый. Беренче шигырьләр, беренче иҗат тәҗрибәләре шушы елларга туры килә. 1960 елда аның балалар өчен "Минем дусларым" исемле шигырьләр китабы дөнья күрә. Шул елдан башлап дистәләгән шигырь һәм җыр җыентыклары, проза һәм тәрҗемә әсәрләре язучы каләме аша үтеп, йөз меңнәрчә укучыны шатландыра. Резеда Вәлиева – кече һәм урта яшьтәге укучыларының җаны ни теләгәнен белеп иҗат итә. Кызыклы, мавыктыргыч, шаянлыкка һәм тапкырлыкка корылган шигырьләр, әкиятләр, поэмалар, (сәхнә әсәрләре) аның каләменнән коелып кына тора.*

***Шигырь. "Оныттым" . Гайфуллина Фәйрүзә.***

***"Замана баласы". Файзрахманова Раилә.***

**1 А.б.** *Шагыйрәнең әсәрләре безне туган якны сөяргә, табигать белән дус булырга, хайваннарны һәм кош-кортларны рәнҗетмәскә, әти-әни сүзен тыңларга, әбиләрне, дәү әниләрне яратырга, туган телгә, туган якка мәхәббәт белән карарга өнди.*

***Шигырь. "И газиз туган телем". Низамутдинова Миләүшә.***

*Сорау.* ________________________________________________

**2 А.б.** *Исем китеп карап торам*

*Синдәй гүзәл сирәк икән.*

*Бәхет өчен, туган җирем*

*Миңа тик син кирәк икән.*

*Үзеннән үзе көй сорап торучы юлларның әлегә кадәр җыр булып китмәүләре гаҗәпләндерә. Резеда апаның өч йөздән артык җыр тексты авторы икәнен белү генә күңелне тынычландыра. Аның шигырьләрен композиторларыбыз ярата, үз итә. Җырлары һәрвакытта*

өлкәннәр тарафыннан да, балалар тарафыннан да яратып кабул ителә.

***Җырлар. " Яран гөл".***

***"Туган көнең белән әнием". Ахметханов Рөстәм***

***Шигырь. "Улыма" Альтапова Рәмзия.***

***<u>Сорау.</u> Резеда апа бу шигырегез безгә аеруча ошады. Шушы шигырегезнең язылу тарихы белән безне таныштырып китмәссезме?***

***1 А.б.*** *Сөйкемле шагыйрәнең җимешле иҗаты бигрәк тә нәни дусларыбызны сөендерә. Аның шигырьләрендә, әкиятләрендә, поэмаларында тирән фикер дә, тәэсирле сурәт тә, ярсу характер да, көлдергеч юмор да, күңелгә уелып кала торган матурлык та бар.*
***Шигырьләр. "Сыер эзләгәндә" Галимуллина Илвира***

***"Ишек алды бозлавык" Шакирова Гүзәл.***

***2 А.б.*** *Безне күренекле шагыйрә, балалар язучысы Резеда Вәлиева белән очраштырган, гомумән бүгенге көндә авылыбыз, җирлегебез өчен күп игелекле эшләр кылучы эшмәкәр, мәктәбебезнең элеккеге укучысы Нияз Гәрәев үзе дә шигырьләр иҗат итә. Нияз, сүзне сезгә бирәбез. Рәхим итегез.*

*Рәхмәт , Нияз. Сезгә иҗат уңышлары телибез.*

***1 А.б.*** *Резеда апа Вәлиеваның шигырләре шундый аңлаешлы, гади, ягымлы тел, җиңел рифмә белән язылган. Тел белмәгән балаларга да тел ачкычы бирердәй аның әсәрләре. Директорыбыз Тәбрик Василович та шигърияткә битараф түгел. Аның да Резеда апага әйтер сүзләре бардыр. Сүзне сезгә бирәбез Тәбрик абый. Рәхмәт сезгә Резеда апа безнең әдәбиятыбызны, җыр һәм шигырьләрегез, хикәя һәм әкиятләрегез, тәрҗемә әсәрләрегез белән баеткан өчен. Әле бүгенге көндә дә укучылар сездән матур-матур иҗат җимешләре көтә. Шуңа күрә сезгә алдагы көнегездә ныклы сәламәтлек, бәхетле картлык телибез. Иҗат чишмәгез беркайчан да саекмасын, сезнең белән әле тагын очрашырга насыйп булсын! Ә сезгә хәзер залга төшеп, укучыларыбызның, очрашу истәлеге итеп башкарган татар халык биюен карарга тәкъдим итәбез.*